# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## О внесении изменения в статью 8 Закона Республики Татарстан «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан»

Принят<br>Государственным Советом<br>Республики Татарстан<br>18 ноября 2022 года

**Статья 1**

Внести в статью 8 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 12 (II часть), № 12 (III часть); 2005, № 2; 2006, № 2 (I часть); 2007, № 11; 2008, № 5 (I часть), № 12 (I часть); 2009, № 12 (I часть); 2010, № 10 (II часть); 2011, № 8 (I часть), № 10 (I часть); 2012, № 6 (I часть), № 7 (I часть); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II часть), № 7, № 12 (II часть); 2015, № 4, № 12 (I часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 44 (часть I); 2018, № 1 (часть I), № 38 (часть I), № 78 (часть I); 2019, № 2 (часть I); 2020, № 57 (часть I), № 87 (часть I); 2021, № 20 (часть I), № 49 (часть I); 2022, № 3 (часть I), № 17 (часть I) изменение, дополнив ее пунктом $4^1$ следующего содержания:

«$4^1$. Лицам из числа детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, лицам, потерявшим в период обучения обоих родителей или единственного родителя, обучающимся по образовательным программам основного общего, среднего общего образования за счет средств бюджета Республики Татарстан или местных бюджетов, наряду с полным государственным обеспечением (за исключением предоставления жилого помещения в порядке, предусмотренном Федеральным законом от 29 декабря 2012 года № 273-ФЗ «Об образовании в Российской Федерации») до завершения их обучения по указанным образовательным программам выплачивается ежегодное пособие на приобретение учебной литературы и письменных принадлежностей в размере трехмесячной государственной социальной стипендии.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу по истечении 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
01 декабря 2022 года
№ 89-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 18 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«$4^1$. Татарстан Республикасы бюджеты яисә җирле бюджетлар акчалары исәбеннән төп гомуми, урта гомуми белем бирү уку-укыту программалары буенча белем алучы ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга, уку чорында ата-анасын яисә бердәнбер атасын йә анасын югалткан затларга тулы дәүләт тәэминаты («Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә торак урыны бирүдән тыш) белән бирәттән, аларның әлеге уку-укыту программалары буенча укулары тәмамланганчы, уку әдәбияты һәм язма әсбаплар сатып алуга өч айлык дәүләт социаль стипендиясе күләмендә еллык пособие түләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 01 декабрь
№ 89-ТРЗ